КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 март г.Казань № 207

2022 елда автомобиль транспорты (төбәкара маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларыннан башка), шәһәр җир өсте электр транспорты, метрополитен белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларында 18 яшьтән өлкәнрәк пассажирларның «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан (gosuslugi.ru) файдаланып алынган, яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясауны яки әлеге авыру белән авыру фактын раслый торган гамәлдәге шәхси QR-кодлары, яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясарга ярамый торган медицина билгеләре булуны раслый торган гамәлдәге шәхси QR-кодлары булуны тикшерү өчен җиһаз сатып алуга һәм элемтә хезмәтләренә түләүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең

кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалкан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022 елда автомобиль транспорты (төбәкара маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларыннан башка), шәһәр җир өсте электр транспорты, метрополитен белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларында 18 яшьтән өлкәнрәк пассажирларның «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан (gosuslugi.ru) файдаланып алынган, яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясауны яки әлеге авыру белән авыру фактын раслый торган гамәлдәге шәхси QR-кодлары, яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясарга ярамый торган медицина билгеләре булуны раслый торган гамәлдәге шәхси QR-кодлары булуны тикшерү өчен җиһаз сатып алуга һәм элемтә хезмәтләренә түләүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин